**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 185 - 16.06.2021

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 14 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын (референдум участокларын) төзү турында» 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 19 статьясы нигезендә, сайлау участоклары урнашкан биналарга капиталь ремонт ясау белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 14 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын (референдум участокларын) төзү турында» 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә урнашкан сайлау участоклары (референдум участоклары) » кушымтасында

20 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«20. 897 нче сайлау участогы (Кормаш). Үзәк - Кормаш авыл клубы, Кормаш авылы, Яшьләр урамы, 43 йорт, 34-1-26. Сайлау участогы чикләренә Кормаш авылы, Рус Ыңдырчысы авылы керә. Сайлаучылар саны - 144;»;

34 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«34. 911 нче сайлау участогы (Чәтбаш). Үзәк - Чатбаш авыл клубы, Чатбаш авылы, Татарстан ур., 51 йорт, тел: 37-2-82. Сайлау участогы чикләренә Чәтбаш, Иске Көлкәш авыллары керә. Сайлаучылар саны-63;»;

50 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«50. 927 нче сайлау участогы (Багыш). Үзәк - Багыш күп функцияле үзәге, Багыш ав., Яшел ур., 21а йорты, тел: 38-0-78. Сайлау участогы чигенә Багыш авылы керә. Сайлаучылар саны -269;»;

55 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«55. 932 нче сайлау участогы (Түбән Биябаш). Үзәк - Түбән Биябаш авыл клубы, Түбән Биябаш авылы, Г.Тукай ур., 20 йорт, тел: 36-0-26. Сайлау участогы чикләренә Түбән Биябаш авылы керә. Сайлаучылар саны - 147;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**